ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

4 март, 2024 ел № 32/9

2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2023 елның 6 декабрендәге 28/11 номерлы Карары белән расланган 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) 6 пунктның 2-3 пунктчаларын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| № т/б | Предприятие исеме | Адресы | Икътисадый эшчәнлекнең төп төре | Үзгәртү |
|---|---|---|---|---|
| 2 | «Мәдәният һәм ял паркы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | 423821, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 81 йорт | Башка төркемнәргә кертелмәгән тамаша-күңел ачу эшчәнлеге | Устав капиталында 100% муниципаль берәмлек өлеше белән акционерлык җәмгыяте |
| 3 | «Шәһәр коммуналь хуалыгы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесе | 423801, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Лермонтов урамы, 54 йорт | Коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге, шәһәр һәм шәһәр янында пассажирлар йөртү | Устав капиталында 100% муниципаль берәмлек өлеше белән акционерлык җәмгыяте |

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев